Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

_23.04.2026 Менделеевск ш. № _282

Менделеевск муниципаль районында
Бердәм дежур-диспетчерлык хезмәте
турында нигезләмәгә үзгәрешләр
кертү хакында

"Гражданнар оборонасы турында" Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында" 2025 елның 23 июлендәге 240-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 21 февралендәге 102 нче номерлы карары белән расланган Менделеевск муниципаль районы Бердәм дежур-диспетчерлык хезмәте турында нигезләмәнең 1.2 пунктындагы 2, 6, 8 абзацларын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Гражданнар оборонасы-Россия Федерациясе территориясендә халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында барлыкка килә торган куркынычлардан яклауга әзерләү һәм яклау чаралары системасы;

халыкны эвакуацияләү-хәвефле зоналардан халыкны оешкан рәвештә күчерү һәм аны хәвефсез районнарга урнаштыру чаралары комплексы;

халыкка хәбәр итү-куркынычлар турында хәбәр итү сигналларын һәм ашыгыч мәгълүматны халыкка җиткерү;".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең шәһәр хуҗалыгы буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р.Искаков